# ИҢ КҮҢЕЛЛЕ КӨН

Бәйрәмнәр турында шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2011

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
И99

Т ө з ү ч е - м ө х ә р р и р е
*Эльвира Кәлимуллина*

И99 Иң күңелле көн : бәйрәмнәр турында шигырьләр / төз. Э.Кәлимуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2011. – 95 б.
ISBN 978-5-298-01965-1

Җыентыкта бәйрәмнәр хакында шигырьләр тупланды. Сүз алып барылачак бәйрәм турында һәр бүлек башында кыскача мәгълүмат та бирелде. Алар аша укучы борынгы төркиләрдә Яңа ел бәйрәменең март аена туры килүен һәм «Нәүрүз» дип аталуын, илебездә 8 Март бәйрәменең беренче тапкыр 1913 елда бәйрәм ителүен, элегрәк Сабантуй бәйрәме алдыннан ботка пешерү, «ат аягы кыздыру» кебек йолалар булуын белер.

«Иң күңелле көн» китабы, бәйрәм-иртәләр, кичәләр уздырганда, өстәмә ярдәмлек булыр. Ул кече һәм урта яшьтәге мәктәп балаларына адреслана. Җыентыктан шулай ук ата-аналар, тәрбиячеләр, укытучылар, бәйрәмнәрнең килеп чыгышы һәм халкыбыз тарихы белән кызыксынучы киң катлам укучылар да файдалана ала.

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01965-1

© Татарстан китап нәшрияты, 2011
© Кәлимуллина Э.Т., төзү, 2011

*Габдулла Тукай*

## БӘЙРӘМ БҮГЕН

*(җыр*)*

Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген.
Нәрсәдән бу? – Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Бер мөкатдәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;
Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!

Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын:
«Ул киенгәндер», – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Хис итеп һәр җирдә дә бертөрле хуш ис аңкуын:
«Ислемай сөрткән икән дөнья!» – дидем: бәйрәм бүген!

Бер теләнчене кочаклашкан күреп бер бай белән:
«Күңле нечкәргән!» – дидем: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!

Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:
Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;
Ансы да сөйли тагын: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!»

---

* Җәүдәт Фәйзи музыкасы.

# ЯҢА ЕЛ КИЛӘ!

*(Яңа ел бәйрәме)*

Яңа ел — иң борынгы бәйрәмнәрнең берсе. Аны бөтен Җир шарында беләләр һәм, әлбәттә, бик теләп бәйрәм итәләр.

Яңа елның Месопотамиядә* барлыкка килүен күпләр әле белми дә торгандыр. Элекке вакытларда Месопотамия халкы, Тигр һәм Евфрат елгаларында су артканнан соң гына, җир эшләрен башлап җибәрә торган булган. Суның артуы яман көчләрне җиңгән Марук алланың килүен, ягъни, яңа елның башлануын аңлаткан. Шул уңайдан халык 12 көн буе бәйрәм иткән. Бу көннәрдә эшләү, җәзалау, хөкем итү тыелган. Әлеге көнне һәр кеше ирекле булган, үзе теләгән нәрсә белән генә шөгыльләнгән.

Күп кенә халыклар Кояш һәм Ай календаре буенча яшәгәннәр һәм аларда ел башы йә көзгә, йә кышка — төрле вакытка туры килгән. Ләкин Яңа елны каршылау күп вакыт март аенда уздырылган, чөнки нәкъ менә бу айда табигать уянган, бөтен тереклеккә җан кергән.

Яңа елны борынгы мисырлылар да бәйрәм иткән. Аларда Яңа ел сентябрь ахырына — Нил елгасында су күтәрелгән вакытка туры килгән. Традиция буенча, Аман алланың һәм аның хатынының, улының сыннарын көймәгә куйганнар һәм Нил буйлап агызып җибәргәннәр. Мисыр халкы аны төрле биюләр һәм җырлар белән озата барган.

---

* Месопотамия — Тигр һәм Евфрат елгаларының урта һәм түбән агымы арасындагы территория (Көнбатыш Азиядә). Борынгы цивилизация учакларының берсе.

Рим халкы Яңа елны мартта каршылаган. Бәйрәм вакытында патша берничә көнгә шәһәрне калдырып киткән, ә халык, хаким булмаудан файдаланып, рәхәтләнеп күңел ачкан. Римлылар бу көнне бик теләп бер-берсенә җиләк-җимеш, тиен (акча), хәтта кыйммәтле бүләкләр дә биргәннәр. Патша шәһәргә кайткач, яңадан «яңа тормыш», «яңа ел» башланган. Римлыларда март ае беренче ай булып саналган, чөнки бу көнне кыр эшләрен башлый торган булганнар.

Безнең эрага кадәр 45 елда Рим императоры Юлий Цезарь ел башын 1 гыйнварга күчерә. Чөнки гыйнвар ае римлыларда Янус алла ае булып саналган, ул берьюлы үткәнгә дә, киләчәккә дә караган. Янус, яктылык алласы буларак, күк капкалары аша якты көнне кертә торган булган. Шуңа күрә әлеге ай ел беткәннән соң һәм икенче ел башланган җирдә урын алырга тиеш булган. Ә яңа календарь исә шул рәвешле Юлиан календаре дип атала башлаган һәм бөтен Европага таралган.

Россиядә Яңа ел бик зурлап уздырыла. Бу көнне һәр җирдән мандарин һәм ылыс исе килә. Йорт-җирләр яхшылап җыештырылганнан соң, мул итеп табын әзерләнә. Өстәлгә, көнчыгыш календаре буенча кайсы ел килүенә карап, ризыклар куела. Күсе елында сырдан әзерләнгән ашамлыклар пешерелсә, песи елында сөт ризыклары кулай күрелә. Бәйрәм көнне бар җирдә яшел чыршы балкып утыра. Балалар чыршы тирәли әйлән-бәйлән уйныйлар. Төрле җәнлекләр, әкият геройлары булып киенәләр, үз һөнәрләрен күрсәтәләр.

Россиядә беренче Яңа ел чыршысы Мәскәү шәһәренең сәүдә мәйданына куела. 1699 елда Петр I Указы буенча, урамнарга, атаклы кешеләрнең капкалары каршына нарат яки чыршы бизәп куярга, ярлырак йортларның капкаларына ылыс ботаклары булса да элергә кушылган.

Беренче чыршы бәйрәме исә 1852 елда булган. Бу бәйрәм хәрби оркестр концерты белән башланган, аннан соң биредә фокусчылар, кәмитчеләр, өйрәтелгән хайваннар чыгыш ясаган. Караңгы төшкәч, чыршыда шәмнәр кабынган.

Яңа ел бәйрәменең үзәгендә Кыш бабай һәм Кар кызы тора. Алар, балаларны биетеп, җырлатып, сынап, бүләкләр, күчтәнәчләр

өләшәләр. Кыш бабайны, ак атларга (боланнарга) тарантас җигеп, күктән төшә дип уйлаганнар. Ул Вологда өлкәсенең Бөек Устюг шәһәрендәге «өендә» хатлар кабул итеп утыра, имеш.

Германиядә Кыш бабайны Николлаус, Голландиядә Клаас, Англиядә Клаус исеме белән атыйлар. Кар кызы исә — Кыш бабайның оныгы.

Курантлар төнге уникене сукканда, һәр кеше теләкләр әйтә, яңа елда тормышка ашырасы хыялларын барлый.

***Син беләсеңме?***

* * *

*Италиядә Яңа елны Кыш бабай түгел, ә тылсымчы Бефалия алып килә. Ул төнлә морҗадан өйгә төшә дә балаларга бүләкләр калдыра. Балалар аны бик ярataлар, аның хөрмәтенә урамнарда бәйрәм ясыйлар. Бефалия үзе кулына факел тоткан кара курчак рәвешендә була.*

* * *

*Италия шәһәрләрендә Яңа ел төнендә урамда, йоклап йөрсәң, башсыз калырга да мөмкин: монда иске елның соңгы минутында төрле чүп-чарны, иске җиһазларны тәрәзәдән урамга ыргыталар.*

* * *

*Шотландиядә иске елның соңгы секундында ишекләрне ачып куялар. Бу иске елны озату һәм яңа елны кертү өчен эшләнә.*

*Данис Хәбибуллин*

## КЕРМИЧӘ КИТМӘС

Җиргә кар ятты, –
Нинди сөенеч!
Суык бабай да
Килергә тиеш.

Узган ел да ул
Кар яугач килде.
Ә капчыгында –
Җаның ни тели.

Ә быел безнең
Өебез яңа.
Ничек соң хәбәр
Итәргә аңа?

Белер микән без
Кайда торганны?
Эзләп табармы
Безнең урамны?

Шуңа мин бераз
Борчылып йөрим.
Кар яуган саен,
Юлларны күрим.

Ишегалларын
Чип-чиста иткәч,
Суык бабай һич
Кермичә китмәс.

*Җәвад Тәрҗеманов*

## ЯШЕЛ ЧЫРШЫ

*(җыр*)*

Тышта буран бөтен җиргә
Карлар тутыра,
Безнең бүлмәдә ямь-яшел
Чыршы утыра.

К у ш ы м т а:

Бүген бәйрәм!
Әйлән-бәйлән
Уйныйк, гөрләшик.
Бүген бәйрәм!
Бәйләм-бәйләм
Бүләк өләшик.

Яшел чыршының очына
Йолдыз куелган.
Яңа елны каршыларга
Дуслар җыелган.

К у ш ы м т а.

Яшел чыршы бүлмәбезгә
Хуш ис тарата.
Илебез дә, Кыш бабай да
Безне ярата.

К у ш ы м т а.

* Заһид Хәбибуллин музыкасы.

Тышта буран бөтен җиргә
Карлар тутыра,
Безнең бүлмәдә ямь-яшел
Чыршы утыра.

Кушымта.

*Резеда Вәлиева*

## ЯҢА ЕЛ

Җем-җем көмеш тун кигән,
Яңа, яңа ел килгән,
Яшел чыршылар белән,
Яңа җырчылар белән.

Яңа, яңа, яңа ел,
Бүген шундый яңа ул.
Яшел чыршы очында
Йолдыз булып яна ул!

Дуслар бергә җыелдык,
Бергә шундый күп булдык,
Әйлән-бәйлән уйнарга,
Кулны кулга тотындык.

Яңа, яңа, яңа ел,
Бүген шундый яңа ул.
Яшел чыршы очында
Йолдыз булып яна ул!

*Әхмәт Ерикәй*

## КЫШ

*(җыр*)*

Биек, биек тау битендә
Чана шуып уйныйбыз.
Ярышабыз, узышабыз,
Матур җырлар җырлыйбыз.

Тау башына менәбез дә
Җил уйнатып төшәбез.
Кошлар сыман бер-бер артлы
Түбән таба очабыз.

Шәп шуалар, ашкыналар
Безнең ярсу чаналар.
Бар урамнан җыелганнар
Тау шуарга балалар.

---

* Мансур Мозаффаров музыкасы.

*Мәрзия Фәйзуллина*

## КЫШ БАБАЙ

Җилкәсенә капчык асып,
Кыш бабай килеп керде.
Төрле кызык сүзләр әйтеп,
Бүләк өләшеп йөрде.

Аннан Кыш бабай, тыпырдап,
Бик шәп бии башлады.
Биемәскә, аягында –
Безнең апа башмагы.

*Әхмәт Рәшит*

## КЫШ БАБАЙ

Кыш бабай, Кыш бабай,
Безгә бик таныш бабай;
Сакал-мыек ап-актан,
Килгән безгә еcontainerактан.

Бүләкләр алып килгән,
Бүреген кыңгыр кигән –
Әйлән-бәйлән уйната,
Биетә һәм җырлата.

Безгә конфетлар бирә,
Үзе елмая-көлә,
Кыш бабай безгә тагын
Яңа ел алып килә.

*Хәкимҗан Халиков*

## КЫШ БАБАЙ

Яратам мин Кыш бабайны,
Шундый шаян бабай ул:
Безнең белән уйнаганда,
Әйтерсең бер малай ул.

Җырласа да, биесә дә,
Хәзер инде бик карт ул.
Дәү әтием кебек үзе,
Шулкадәрле юмарт ул.

Миңа бирде машинаның
Үзе йөри торганын,
Ә конфетның – кабу белән
Балдай эри торганын...

Белсәң иде, яшь чакта ул
Кем кебек булды икән?
Ул чакта да хәзергедәй
Гел көлеп торды микән?
Шундый шат булды микән?
Бик юмарт булды микән?

*Әнәс Кари*

## КЫШ БАБАЙ БҮЛӘКЛӘРЕ

Матур бәйрәм җырыбыз
Яңгырагач еракка,
Кыш бабабыз ишетеп
Килде безгә кунакка.

Елмаеп ул эндәшә:
«Исәнмесез, дусларым!
Ямьле бәйрәм кичендә
Яусын сезгә котлавым.

Нинди әйбәт уйныйсыз
Яшел чыршы янында.
Бүләк биреп, мин сезне
Шатландырыйм тагын да.

Чикләвекләр җибәрде
Җитез тиен урманнан,
Баллы ап-ак күмәчләр –
Бүләк сезгә куяннан.

Дус-ишләре каршында
Калмас өчен көлкегә,
Перәннекләр, конфетлар
Төреп бирде төлке дә...

Менә тагын әфлисун,
Нинди пешкән – күрегез;
Боларны соң җәнлекләр
Каян алган – белегез...»

## КЫШ

Юеш көннәрдә
Зарыгып беттек,
Кыш бабабызны
Сагынып көттек.

Без нәниләрне
Кыш та сагынган,
Төнлә килеп ул
Карлар яудырган.

Кар яуган! Яуган
Мамык кебек кар,
Ап-ак булганнар
Урамнар, кырлар.

Бәскә төренгән
Агач башлары...
Бүгеннән безгә
Бәйрәм башланды!

Җыелып бергә,
Тауга чыгабыз,
Шаулашып анда
Чана шуабыз.

Кычкырабыз без
Бергәләп: На-на!
Курыкмыйбыз һич –
Чанабыз яңа.

*Нур Гайсин*

## БЕР ЯШЬКӘ ҮСТЕМ

Көн салкын, тышта
Уйный кар-буран,
Ак төскә керде –
Бизәлде урам.

Тагын ямьлерәк
Итәргә илне,
Иске ел үтеп,
Яңа ел килде.

Ямьле Кыш бабай,
Килдең син безгә,
Кунак булырсың,
Кер өебезгә.

Кыш бабай, мине
Бүген син макта,
Бер яшькә үстем,
Син килгән чакта.

*Роберт Миңнуллин*

## ЧЫРШЫ ӘЙЛӘНӘСЕНДӘ

Каршылыйк, дуслар, бергәләп:
Яңа ел килә безгә!
Әнә күпме кунак килгән
Әйләнә-тирәбезгә.

Йолдызлар төшеп кушылган
Чыршыдагы утларга.
Кыш бабай белән Кар кызы
Килгән безне котларга.

Кыш бабай килгәч булачак
Котлаулар да, бүләк тә!
Яңа елда чынга ашар
Безнең бөтен теләк тә!

Яңа елның бәхетле ел
Буласын без беләбез.
Шуңа күрә бергәләшеп
Яңа елга керәбез.

Рәхмәт сиңа да, иске ел!
Матур ел булдың бит син.
Синнән алган бәхет-шатлык
Гомер буена җитсен!

# КАР БӘЙРӘМЕ

Кара гына, кар агыла
Безнең авыл ягына.
Әй ява кар, өр-яңа кар
Безнең авылга гына.

Кар бәйрәме, кар бәйрәме!
Куаныч – кар булганда.
Ак кызлар да ак малайлар
Уйный бүген урамда.

Чүпрә кебек күперә кар –
Кар тездән, кар муеннан...
Кар уены, кар уены
Кызыграк бар уеннан!

Кирәк түгел Карбабай да,
Явып торгач кар алай.
Һәр кыз бүген Кар кызы бит,
Һәрбер малай – Карбабай!

*Әминә Бикчәнтәева*

## ЧЫРШЫ ЯНЫНДА

Яшел чыршы, тизелешеп
Әйләнәбез тирәңдә,
Куанабыз Яңа елга
Син кунакка килгәнгә.

Җәй көне җиләк җыярга
Урманга барган идек:
– Ямьле чыршы, Яңа елга
Кунак булып кил, – дидек.

Рәхмәт, менә син килгәнсең,
Әйләнәбез тирәңдә,
Яңа һөнәрләр өйрәндек,
Яңа елга кергәндә.

*Галимҗан Латыйп*

## ЯҢА ЕЛ

*(кыскартып бирелә)*

Безнең чыршыбызны бизәп,
Балкып кабына утлар,
Яңа елның башлануын
Хәбәр итә курантлар.

Кыш бабай, Кыш бабай
Безне бик ярата,
Ул безгә Яңа ел
Бүләге тарата.

Ак чәчәк кебек кар ява
Урманнарга, кырларга.
Тынычлык алып Яңа ел
Килсен бөтен дөньяга.

*Муса Җәлил*

## СУЫК БАБАЙ

*(кыскартып бирелә)*

Суык бабай, кил безгә
Яңа ел бәйрәменә,
Чыршы әйләнәсендә
Җыр җырлап әйләнергә.

Ефәк кушак* билеңдә,
Көмеш балта кулыңда,
Зифа буйлы бер чыршы
Үсеп тора юлыңда.

Балтаң белән чыршыны
Кисеп аудар чанаңа;
Ул, киенеп, ясанып,
Килсен безнең арага.

Уенчыклар, бүләкләр
Безгә тагын алып кил,
Соңга калма, бабакай,
Атлап түгел, чабып кил.

---

* Кушак – билбау, пута.

*Дамир Гарифуллин*

## КАР БАБАЙ ЯСАДЫК

Җыелышып, җепшек кардан
Кар бабай ясап куйдык.
Матурлап аның күзләрен,
Авызын хәтта уйдык.

Нинди эш кушыйк аңа дип,
Кичен уйлап тордык та –
Каравылга дип калдырдык
Бер таяк тоттырдык та.

*Сәхаб Урайский*

## ЧЫРШЫ ЯНЫНДА

*(җыр*, поэмадан өзек)*

Чыршы, чыршы, без сине
Сагынып көттек ел буе,
Син тагын да матур(ы)рак
Бизәлгәнсең бу юлы.

Энҗе карлар явып үткән
Яшел ылысларыңа,
Күп бүләкләр китергәнсең
Без нәни дусларыңа.

---

* Исмай Шәмсетдинов музыкасы.

Без уйныйбыз, җырлыйбыз,
Шатланабыз, көләбез.
Безгә рәхәт тормыш биргән
Илебезне сөябез.

*Ләбиб Лерон*

## ХУШ КИЛӘСЕҢ, ЯҢА ЕЛ!

Янә бер ел артта калды,
Калды артта моңаеп...
Ниләр безгә вәгъдә итә? –
Алдыбызда Яңа ел!

Булыр микән йөзе һәрчак
Кояш кебек гел көләч?
Куандырыр микән безне
Һәрбер көне – ул килгәч?!

И Яңа ел, балкып кил син,
Шатлык белән генә кил:
Әтиләр дә, әниләр дә,
Бабайлар да, әбиләр дә,
Апалар да, абыйлар да,
Һәм, әлбәттә, сабыйлар да
Сөенсеннәр гелән-гел!
Хуш киләсең, Яңа ел!

# СОЛДАТ БУЛАСЫМ КИЛӘ!

*(Ватанны саклаучылар көне)*

Бу көнне без бар ир-егетләрне бәйрәм белән котлыйбыз, бүләкләр бирәбез, алар өчен тәмле ризыклар пешерәбез. Чөнки 23 февраль — Ватанны саклаучылар көне.

Бәйрәмнең тарихы совет чоры белән бәйләнгән. 1917 елда Совет хөкүмәте, властька килгәч үк, катлаулы хәл алдында кала. Чөнки инде Беренче бөтендөнья сугышы башланган була. Илне дошманнардан саклау өчен 1918 елда Халык комиссарлары советы рәисе В.И.Ленин «Эшче-крестьян Кызыл Армиясе төзү» турында, соңрак шулай ук «Эшче-крестьян Кызыл Флотын төзү» турында декрет кабул итә. Кызыл Армиягә һәм Кызыл Флотка үз иреге белән илне сакларга теләүче эшчеләр кабул ителә.

1917 елның 23 февралендә беренче тапкыр Кызыл Армия көне уздырыла. Тагын бер елдан нәкъ шушы көнне Кызыл Армия Псков һәм Нарва янында немец гаскәрләрен җиңүгә ирешә.

1922 елдан исә әлеге дата рәсми рәвештә Кызыл Армия көне дип игълан ителә. Шуннан соң ул ел саен билгеләп үтелә башлый. 1946 елдан 23 февраль «Совет Армиясе һәм Хәрби диңгез флоты көне» буларак бәйрәм ителә. Бары 2005 елда гына әлеге бәйрәм «Ватанны саклаучылар көне» дип атала башлый.

Күпләр өчен 23 февраль көне армиядә яки хәрби урыннарда хезмәт итүче ир-егетләр бәйрәме булып калды. Шулай да бүген бәйрәм ир-егетләр көне, безнең яклаучыларыбыз көне буларак бәйрәм ителә. Бу көнне хәрби органнарда эшләүчеләрдән алып бакчага йөрүче кечкенә малайларга кадәр котлаулар кабул итә. Алар хөрмәтенә кичәләр, концертлар оештырыла. Озак еллар эш көне булып кала биргән 23 февраль исә соңгы елларда ял көне итеп үзгәртелде.

*Клара Булатова*

## СОЛДАТЛАР

Бабай да солдат булган,
Эти дә солдат булган.
Зур абый да, солдат булып,
Ил чикләрендә торган...

Кече абый солдат булып
Китте быел яз гына,
Мин үзем дә солдат булам,
Үсим генә аз гына.

*Шамил Маннапов*

## СОЛДАТТА БУЛГАН, ДИЛӘР...

*(җыр*, кыскартып бирелә)*

Билен кысып буган, диләр,
Биг(е)рәк уңган, диләр.
Әллә каян күренеп тора –
Солдатта булган, диләр.

Кечеләрне кече итәр,
Олыны зурлар, диләр.
Әллә каян күренеп тора –
Солдатта булган, диләр.

Комбинезон алган, диләр,
Шинелен салган, диләр.
Шинелен салса да солдат,
Гадәте калган, диләр.

---

* Гариф Нигъмәтҗанов музыкасы.

*Роберт Миңнуллин*

## ПОЧМАКТА ТОРАМ

Әни почмакка
Бастыра мине,
Нигә икәнен
Беләсез инде!

Чыкмый тыным да,
Еламыйм хәтта.
Елау турында
Уйламыйм хәтта.

Торам төз генә,
Телләшми генә,
Сер бирми генә,
Сөйләшми генә.

Әзер мин монда
Көн дә торырга –
Өйрәнәм бит мин
Солдат булырга!

Солдат булырга –
Сакта торырга!

*Җәүдәт Дәрзаман*

## СОЛДАТ БУЛДЫМ

Каеш будым билемә,
Тасма тактым җиңемә,
Йолдызлы бүрек кидем,
– Мин солдат булдым! – дидем.
Иңемә мылтык астым,
Әти каршына бастым:
Килдем, иптәш командир,
Әйдә бирәр фәрман бир!
– Смирно! – диде әти дә, –
Печән ашат бәтигә.
Бераз утын ярырсың,
Аннан... суга барырсың!
Шуннан китте, и китте,
Миннән чын солдат итте.
Бетте ялкау гадәтем,
Санаулы һәр сәгатем.
Иртүк торам, юынам,
Сөлге белән уынам,
Ялт иттерәм тешләрне,
Аннан эшлим эшләрне.
Бүлмәмдә тәртип хәзер,
Ни кирәксә, шул әзер.
Солдат булу шулай ул,
Өйрәнгәч, бик уңай ул!

*Шәүкәт Галиев*

## БУСЫ – ХӘРБИ СЕР!

Еракта-еракта тора,
Минем абый сакта тора.
Әни эштә чакта тора,
Әти юлда чакта тора,
Мин уйнаган чакта тора,
Син йоклаган чакта тора!

Телевизор да карамый,
Читкә карарга ярамый,
Чиккә генә карап тора,
Дошман килеп кермәсен, ди,
Безнең серне белмәсен, ди.

Әниләр эштә булганда,
Берүзең генә калганда,
Түгел өйне саклап тору,
Бу бит – илне саклап тору!

Еракта-еракта тора,
Минем абый сакта тора.
Сакта һәр-һәр чакта тора.
Әйтмим, кайсы якта тора,
Син үзең дә сорап торма,
Бусы – хәрби сер!

# БҮГЕН ӘНИ БӘЙРӘМЕ!

*(8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне)*

Бу көнгә бар кеше, башкаларга сиздерми генә, әнисенә, әбисенә, сеңлесенә, укытучы апасына, иптәш кызларына бүләкләр әзерли. Ул көнне барлык ирләр, ничә яшьтә булуларына карамастан, һәммә хатын-кызларга карата аеруча игътибарлы булалар. 8 Март — дөньядагы барлык хатын-кызларның бәйрәме.

Әлеге бәйрәмнең барлыкка килүе хатын-кызларның үз хокукларын яклау тарихына барып тоташа. 1857 елның 8 Мартында Америка Кушма Штатларының Нью-Йорк шәһәрендә тегү фабрикаларында эшләүче хатын-кызлар манифестка җыела. Чөнки дөньядагы барлык хатын-кызларга да яшәү ирләргә караганда авыррак була. Эшче хатын-кызлар бер үк хезмәт өчен түләнгән эш хакын ирләрдән күпкә ким алалар. Врач, инженер, юрист булырга аларның хокукы юк, теләгән уку йортына кереп укырга да хатын-кызларга рөхсәт ителми.

1908 елның 8 Мартында исә алар янә шул ук таләпләр белән митингка чыгалар. Яңгыр сибәли, ләкин халык арта гына бара. Күбесенең кулында балалар. Нью-Йорк эшче хатын-кызлары гаделлек, ирләр белән тигез хокуклы булуны таләп итә.

1910 елда Даниянең Копенгаген шәһәрендә уздырылган социалист хатын-кызларның халыкара конференциясендә Клара Цеткин 1908 ел вакыйгасы хөрмәтенә 8 Мартны Халыкара хатын-кызлар көне буларак билгеләп үтәргә тәкъдим итә.

Бәйрәм беренче тапкыр 1911 елның 19 мартында Австрия, Дания, Германия һәм Швейцариядә билгеләп үтелә. Бу вакытта, хатын-кыз хокукларын яклап, миллионнан артык кеше митингка чыга. 1912 елда исә ул 12 майда уздырыла.

Россиядә әлеге бәйрәм беренче тапкыр 1913 елда Санкт-Петербург шәһәрендә билгеләп үтелә. Шәһәр халкы митингка җыйнала. Биредә хатын-кызларның сайлау хокукы, кеше гомеренең кыйммәте һ.б.лар хакында сүз алып барыла. 1914 елда Европаның күп кенә илләрендә 8 Март көнне хатын-кызлар сугышка каршы маршлар оештыралар.

8 Март — Халыкара хатын-кызлар көне башта ук дәүләт күләмендә уздырыла торган бәйрәмнәрнең берсе була. 1965 елдан исә бу көн ял көне итеп билгеләнә. 8 Март көнендә, гадәттә, дәүләт эшлеклеләре хатын-кызларга карата булган дәүләт сәясәтенең тормышка ашырылуы хакында җавап тотканнар. Тик әкренләп бәйрәмнең сәяси төсе бөтенләй югала.

8 Март көнне барлык хатын-кызларны: әбиләрне, әниләрне, кызларны һ.б.ны котлыйлар. Матур теләкләр әйтеп, чәчәкләр бүләк итәләр. Бу көнне ир-егетләрнең аш бүлмәсендә кайнашуын күрү дә гаҗәп түгел.

***Син беләсеңме?***

*Бик күп еллар элек Борынгы Римда да хатын-кызлар көне булган. Бу көнне хатын-кызлар ир-егетләрдән бүләкләр кабул иткәннәр, иң яхшы киемнәрен киеп, йорт учагын саклаучы Веста алласы храмына килә торган булганнар. Әлеге көнне хәтта кол хатын-кызлар да көндәлек хезмәтләреннән азат ителгән һәм бүләкләр кабул иткән.*

*Гөлшат Зәйнашева*

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ

*(җыр*)*

Беренче тамчылар тама,
Яз килүгә шатланып.
Язлар җиткәч, таңнар ата
Зәңгәрләнеп, сафланып.

Кушымта:

Алып кил безгә, яз,
Чәчәкләр бәйләме.
Килеп җитте матур бәйрәм –
Әниләр бәйрәме.

Әниләр – мәңгелек шатлык,
Язгы шатлык, язгы нур.
Әниләргә багышлана
Дөньяда иң назлы җыр.

Кушымта.

Үз әнкәсе, үз газизе
Һәркемнең күңелендә.
«Әни-әни» дип сайрыйдыр
Кошлар да үз телендә.

Кушымта.

---

* Луиза Батыр-Болгари музыкасы.

# КОЯШ ГОМЕРЕ

*(җыр*)*

Бер кыз бала җыр чыгарган
Багышлап әнисенә.
Икәү бергә җырлыйк, диеп
Өйрәткән энесенә.

Кушымта:

Кояш, кояш
Мәңге балкый,
Мәңге нур сибә.
Кояш гомере телим мин,
Әнием, сиңа!

Җырны чишмәләр ишеткән,
Кошлар отып алганнар.
Сандугачлар һәм тургайлар
Матур көйгә салганнар.

Кушымта.

Кушыл син дә, җырлыйк бергә,
Яңа матур җыр тусын.
Җирдә әниләр кояштай
Озын гомерле булсын.

Кушымта.

---

* Фәтхерахман Әхмәдиев музыкасы.

*Резеда Вәлиева*

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ

Нигә бүген бөтен җирдә
Чәчәкләр балкый бездә,
Нигә кояш көлеп карый,
Беләбез һәммәбез дә.

Бүген әниләр бәйрәме,
Бүген җирдә тантана.
Кояш шуңа көлә бүген,
Гөлләр шуңа шатлана.

Әниләрнең бәйрәменә
Куана шулай алар.
Әниләрне котлый бүген
Җирдә барлык балалар.

Мин дә котлыйм, әнкәм, сине,
Теләгем бар минем дә:
Мәңге шулай кояш кебек
Балкы күңел күгемдә!

*Фәнис Яруллин*

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕНДӘ

Әй ачу чыкты абыйга –
Шундый иртә торган ул.
Мин торганчы, бөтен эшне
Бетергән дә куйган ул.

Утыннар да кисеп керткән,
Ишегалдын көрәгән.
Аның күпме эшләгәнен
Әнием дә күрмәгән.

Әнием мактый абыйны:
– Әй уңган, улым, син, – ди. –
Бөтен эшкә өлгергәнсең,
Минем уң кулым син, – ди.

Ә абыем рәхәтләнеп
Көлеп тора бер читтә.
Көл әйдә, көл, синнән әле
Үч алырмын ничек тә.

Әниләр бәйрәме тагын
Килеп җитәр бер елдан.
Шул чакта күрерсез менә –
Кем өлгер дә кем уңган.

## БУШЛЫК

Өйнең эче яп-ялангач,
Белмимен әллә нигә.
Кайтып керәсе дә килми
Бүген бөтенләй өйгә.

Бөтен нәрсә үз урынында,
Тик җитешми әллә ни...
Әй, онытып торам икән:
Өйдә юк бүген әни!

*Сажидә Сөләйманова*

## ӘНИЛӘР БӘЙРӘМЕ

Кояш көлә, мин елмаям,
Сигезенче Март бүген.
Бүген әниләр бәйрәме,
Шуңа күңелем шат минем.

Кайсын юам, кайсын җыям,
Чиста булсын, ак булсын!
Әниләрнең күңеледәй
Бөтен нәрсә пакь булсын!

Бәйрәм бүген, бәйрәм! – диеп,
Бар дөнья көлеп торсын.
Әни бәйрәме икәнен
Әти дә белеп торсын,
Әти дә көлеп торсын!

## КЕМ УЯТКАН ЛӘЙЛӘНЕ?

Иртүк торып битен юган,
Кем уяткан Ләйләне?
Уятмаган, үзе торган –
Бүген әни бәйрәме.

Пәрдәләрне ачып куйды,
Көн кояшлы, көн ямьле!
Якты булсын, балкып торсын –
Бүген әни бәйрәме.

Өстәл өстен кат-кат сөртте,
Җәйде ап-ак җәймәне.
Чиста булсын, пөхтә булсын –
Бүген әни бәйрәме.

Күмәкләшеп без дә, дуслар,
Җырлап алыйк, әйдә әле:
– Котлы булсын! Гөрләп торсын
Әниләрнең бәйрәме!

*Зәкия Туфайлова*

## «ӘНИ» СҮЗЕ

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

*Җәүдәт Дәрзаман*

## БҮЛӘК

Март бәйрәмен быел бик тә
Зарыгып көткән идем.
Әниемә бүләк эзләп,
Мин арып беткән идем.

Иң матурын алам диеп,
Кая гына чапмадым,
Чыннан бүләк булырдаен
Тик барыбер тапмадым.

Ярар, әни эштә чакта,
Урыннарны җыярмын.
Тузаннарны җыештыргач,
Савыт-саба юармын.

Гөлләренә су сибәрмен,
Җибәрермен аш куеп.
Эштән кайткач, ял итәр бер,
Мендәренә баш куеп.

Җырлый-җырлый эшли торгач,
Узган да киткән вакыт!
Уйларымнан бүлендерде
Әнием, ишек шакып.

Килеп кергәч, кояш кебек
Балкыды әллә нигә.
Мин бүләксез басып торам,
Ни әйтим, дип әнигә...

*Җәвад Тәрҗеманов*

## ӘНИ ТУРЫНДА ҖЫР

*(җыр*)*

Күгәрченнәр гөрләшәләр
Язгы кояш нурында,
Алар җырлый иң матур җыр
Минем әни турында.

Кушымта:

Нинди булган, нинди уңган
Ул һәр эштә, һәркайда!
Йомшак сүзе, күркәм үзе,
Нурлы йөзе елмая.

Кушымта.

Йөрәгемнең иң түрендә
Иң кадерлем – әнием.
Яхшылыкта, якынлыкта
Әниемә тиң илем.

Кушымта.

Күрәсезме, букет итеп
Алсу нурлар бәйләмен,
Кояш котлый март аенда
Минем әни бәйрәмен.

Кушымта.

---

* Заһид Хәбибуллин музыкасы.

*Ренат Харис*

## ӘНИЕМ

Әнием минем матур,
Күзләре якты, көләч.
Шундый күңелле була,
Ул өйгә кайтып кергәч.

Мин елышам әнигә,
Әни миңа елыша.
Битләре аның кайнар,
Ә куллары йоп-йомшак.

Конфет та кирәк түгел,
Кирәк түгел курчак та,
Чөнки мин әниемне
Алдым инде кочаклап.

# НӘҮРҮЗ КИЛӘ, БЕЛӘСЕҢМЕ?

*(Нәүрүз бәйрәме)*

Бабаларыбыз элекке вакытларда Ай һәм Кояш календаре буенча яшәгән. Яңа елның беренче көне итеп көн белән төннең тигезләшкән вакытын (ул 21 мартка туры килгән) исәпләгәннәр. Бу көнне кояш зодиакның Хәмәл йолдызлыгына кергәнгә, айның үзен дә «хәмәл ае» (ягъни март ае) дип йөрткәннәр. Ә татарлар аны «Нәүрүз ае» дип йөрткәннәр. «Нәүрүз» фарсы телендә «яңа көн» дигәнне аңлата.

Бу көнне Яңа елны каршылау белән бәйле җырлар башкарылган. Яңа елны 21 мартта каршылау традициясе Шәрекъ илләрендә безнең эрага кадәр XVI гасырда ук гамәлдә булган. Алга таба ул Һиндстанда да билгеләп үтелә башлаган. Иран, Әфганстан, Азәрбәйҗан кебек Шәрекъ илләрендә бу йола бүген дә саклана. Бу илләрдә Нәүрүз кышны озату, язны каршылау бәйрәме булып тора.

Бәйрәм буласы көнне өйләрне җыештырганнар, тәмле ризыклар пешергәннәр. Нәүрүз бәйрәме көнендә балалар, өйдән өйгә йөреп, нәүрүз әйткәннәр, бүләк җыйганнар. Нәүрүзчеләр йорт хуҗаларына яңа елда исәнлек-саулык, кырларга бай уңыш, мал-туарга мул үрчем теләгәннәр. Нәүрүз куплетлары «Нәүрүз мөбарәкбад!» («Яңа ел котлы булсын!») дигән сүзләр белән тәмамланган. Өй хуҗалары исә балаларның бу изге теләкләренә бүләк итеп конфет, перәнник, тәңкә (акча), пәке, тарак, йомырка биргәннәр. Аннан бөтен авыл халкы бәйрәмгә җыйналган. Табынга йола ашлары әзерләнгән. Өстәлгә шулай ук яшел уҗым да куелган, аңа яңарыш билгесе итеп караганнар.

Нәүрүз бәйрәме күп кенә якларда бүген дә уздырыла. Бу уңайдан бар халык урамга чыга, күңел ача. Иң чибәр, иң уңган кызны Нәүрүзбикә итеп сайлап куялар. Ул Кыш бабай белән ярыша һәм җиңеп чыга. Әнә шулай Кыш бабай рәвешендәге иске ел куып җибәрелә. Бу көнне зур самовар куела, тәмле коймаклар пешерелә. Әлеге сыйдан бөтен кунаклар да авыз итә.

Себер татарларында бәйрәм көнне атка атланып авыл әйләнү, балаларга конфет, перәнник өләшү гадәте саклана. Әстерхан татарларында басуга чыгып намаз уку, йола боткасы ашау гадәте калган.

## *Халык авыз иҗаты*

*(Бәйрәм көнне йорт хуҗаларына әйтелә торган такмаклар)*

* * *

Торыгыз, тор, хуҗалар!
Нәүрүз җитте, беләмсез?
Нәүрүзчеләр килде сезгә,
Ни сөенче бирәсез?

* * *

Нәүрүз, Нәүрүз, хуҗалар!
Ага, эне, җиңгәләр!
Нәүрүз өйгә иңгәләр.
Бәйрәм мөбарәк булсын!

Чип-чип, чибәрүк,
Йомыркасы югарук.
Ак тавык, күк тавык,
Ходай бирсен күп тавык.

* * *

Чиби-чиби, чип тавык,
Куначага мен, тавык.
Куначага меналмасаң,
Чебешеңне җый, тавык.
Әби-бабай, үдәмесең,
Бер җомырка бирәмесең?
Бер җомырка бирмәсәң,
Тимерчегә барырмын,
Тимер тукмак алырмын.

## БЫЛБЫЛДАН АВАЗ КИЛДЕ

Кыш китте, яз килде,
Үрдәк белән каз килде,
Былбылдан аваз килде –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Абзый, эшең уң булсын,
Теләгәнең юш булсын,
Күңелләрең хуш булсын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

Нәүрүз хакы биш алтын,
Бирсәң, ярар ике алтын,
Карама ялтын-йолтын –
Нәүрүз мөбарәк булсын!

***Әхмәт Гадел***

## НӘҮРҮЗ

Әнә яз яшелләнә,
Җир-анабыз гөлләнә,
Бозны тишә ак чәчәк,
Көнгә бага саф чәчәк!

Бүген көн тиң төннәргә,
Урын юк һич көнләргә,
Без дә тиң, без дә тигез!
Мөбарәк Нәүрүз! – дибез.

*Роберт Миңнуллин*

## НӘҮРҮЗ

Хуш киләсең, гүзәл Нәүрүз! –
Язгы яңа елыбыз,
Яңа елда туры булсын,
Нурлы булсын юлыбыз!
Еракларга яңгырасын
Бүген дәртле җырыбыз.

*Роза Хафизова*

## НӘҮРҮЗ КИЛӘ

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Нәүрүзне зурлыйк әле.
Гөрләвекләр челтерәвенә
Кушылып җырлыйк әле.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Илләр, көннәр ямьләнә.
Бергәләшеп биергә дип,
Куллар кулга бәйләнә.

Нәүрүз килә, Нәүрүз килә,
Күктән нурлар сибелә.
Туган илем, туган җирем
Язны күреп сөенә.

# САГЫНЫШЫП КОШЛАР КАЙТА

*(Халыкара кошлар көне)*

Яз көннәре бәйрәмнәргә бай. Шуларның берсе — Халыкара кошлар көне. Ул 1 апрельгә туры килә. Нәкъ шушы көнне бөтен дөньяда канатлы дусларыбызны саклау көне уздырыла.

1906 елның 1 апрелендә кошларны саклау турында дөньякүләм конвенция кабул ителә. Россия Федерациясендә кошлар бәйрәме беренче тапкыр 1927 елның 1 апрелендә билгеләп үтелә башлый. Әлеге елда Мәскәү шәһәрендә кошларга ярдәм йөзеннән меңнән артык сыерчык оясы эленә. Акциядә, балалар, яшүсмерләр белән беррәттән, зурлар да теләп катнаша. «Яшь натуралист», «Тере табигать» кебек журнал битләрендә бу турыда язмалар, өндәмәләр даими басылып тора.

Тик әкренләп кошларны саклау көне онытыла, ә 1 апрель исә күбрәк Көлке көне буларак билгеләп үтелә башлый. 1994 елда бәйрәмгә яңа сулыш өрелә, ул янә зур бер бәйрәм булып әйләнеп кайта.

Бу бәйрәм көнне укучылар ясаган сыерчык ояларын мәктәпкә алып килә. Алар укытучылар белән бергә ояларны түбә кыекларына эләләр. Канатлы дусларыбызга багышланган викториналар, кичәләр уздыралар, театрлар куялар. Табигать белеме, зоология дәресләрендә алган белемнәрен ныгытыр өчен урманнарга, бакчаларга кошларны күзәтергә чыгалар.

*Галимҗан Латыйп*

## КОШЛАР КАЙТКАЧ

*(кыскартып бирелә)*

Елгада бозлар кузгалды...
Елмая, көлә кояш.
Урамнар буйлап атлады
Ямьле һәм күңелле яз.

Килгән кошларны күрергә
Гаяз ашыкты иртән:
– Сыерчык кунган түбәгә,
Кайчан ул килеп җиткән?..

Сузып-сузып сайрый кошчык,
Канатын кага-кага.
– Яратам җырыңны, – диеп
Эндәште Гаяз аңа.

– Ышанмыйм, – диде сыерчык, –
Күңелем минем тоя:
Яраткан булсаң җырымны,
Син куяр идең оя.

*Әнәс Кари*

## ХУШ КИЛДЕГЕЗ, КОШЛАР!

Һаваларда
Шат тавышлар
Ишетелә:
Язны котлап,
Төркем-төркем
Кошлар килә!

Аларны без,
Якын итеп
Каршыларга,
Шатлык белән
Җырлап чыктык
Урамнарга.
Кайткан алар.
Сөеп-сагынып
Илебезне,
Корткычлардан
Чистартырлар
Җиребезне...
Без оялар
Ясап куйдык
Сезгә, кошлар.
Рәхим итеп
Урнашыгыз,
Якын дуслар!

## МИНЕМ КУНАГЫМ

Зур бер бүләк алган сыман,
Чын күңелдән куандым:
Сыерчык килде, сыерчык,
Сагынып көткән кунагым.

Әзерләнеп тордым күптән
Каршыларга дип аны.
Әнә ничек яраткан ул
Мин ясаган ояны.

Тирәсендә очып йөргәч,
Кереп эчен карады:
Яңа өен котлагандай,
Матур итеп сайрады.

*Нури Арсланов*

## КАРА КАРГА

Аны яз кошы диләр,
Еракта кышлый диләр,
Беренче булып кайта да
Ул куа кышны диләр.

Кара карга кар куа, –
Кара җирләр калкуга,
Сабанчы белән бергә
Төшә дә җылы җиргә.
Ул атлап йөри ипләп,
Төрле кортларны чүпләп.

Уйный кояш нурлары –
Ялтырый каурыйлары.
Кояш та кала күреп:
Кем оя салган үреп? –
Талда кара каргаларның
Йортлары бүрек-бүрек.

И матур шушы чаклар!
Бик кадерле кунаклар –
Каргалар кайтты диеп,
Гөр килә ерганаклар.

*Нәҗип Мадьяров*

## СЫЕРЧЫК

Шатлыгы сыймый эченә,
Сайрый ул, сузып-сузып.
Йә әйләнә бытбылдыкка,
Йә җырлый тургай булып.

Бака булып та бакылдый,
Тартар да була ала.
Кызылтүш кебек тә сайрый,
Канатын кага-кага.

Юкка сөенми, аңа бит
Бик ошый яңа оя.
Шуны ясап биргән өчен,
Ул безгә концерт куя.

*Ләбиб Лерон*

## СЫЕРЧЫКЛАР

Җылы яктан очып килде
Сыерчыклар-кошкайлар.
– Исәнмесез, малайлар! – дип
Дәшә безгә дускайлар.

Куанышып сайрашалар
Кояшлы, аяз күктә.
Без аларга кул болгыйбыз:
– Оябыз әзер күптән!

*Шәйхи Маннур*

## КОШЛАР КИЛДЕ

Исәнмесез, кошкайлар,
Безнең якын дускайлар –
Чәүкәләр һәм актүшләр,
Сыерчыклар, тургайлар.

Талмадымы канатлар,
Каршы җилләр искәндә?
Очрадымы кораблар,
Диңгезләрне кичкәндә?

Язга килеп җиттек без,
Сезне сагынып көттек без,
Сезне көткән арада,
Күп дәресләр үттек без.

Күп китаплар укыдык,
Күңелгә нур тутырдык,
Шул китаплар аркылы
Кошларга чын дус булдык.

Хуш киләсез, кошкайлар,
Сайрагыз көнен-төнен.
Кайда ошый?
Сайлагыз –
Җир-сулар бик киң безнең.

*Гасыйм Лотфи*

## СЫЕРЧЫК

*(кыскартып бирелә)*

Өй түрендә – бакчада,
Талчыбык кунакчада
Сыерчык канат кага –
Яз килүгә шатлана.

Җилпенә ул, талпына,
Шатлыктан сайрап куя,
Ак каенның башында
Бик матур оя кора.

Кем ясаган ояны –
Сыерчык белә аны.
Чут-чут итеп сайравы –
Аның оя сайлавы.

## УРА, ҖИҢҮ КИЛДЕ!

*(9 Май — Бөек Җиңү көне)*

1941 елда башланган Бөек Ватан сугышы 1945 елның 9 Маенда гына тәмамлана. Нәкъ шушы көнне Германия капитуляция актына кул куя. Бу СССР тарихында булган иң сөенечле көннәрнең берсе була. Кешеләр җиңү шатлыгыннан урамга агыла. Әлеге көнне хәтта бер-берсен белмәгән, бер-берсе белән таныш булмаганнар да кочаклаша, күрешә, бәйрәм белән котлаша. 9 Май кичендә Мәскәү шәһәрендә моңарчы күрелмәгән салют ясала. Шушы вакыттан 9 Май дәүләт бәйрәме һәм ял көне дип игълан ителә.

Берничә елдан соң 9 Май бәйрәме ял көне булудан туктый. Бары 1965 елда гына ул кабат дәүләт күләмендә билгеләнгән ял көне буларак гамәлгә куела.

***Син беләсеңме?***

*Кайбер чит илләрдә Җиңү көне 9 Майда түгел, ә 8 Майда билгеләп үтелә. Германия капитуляция актына кул куйганда, Европа вакыты 22 сәгать 43 минутны күрсәтә, ә Мәскәү вакыты нәкъ ике сәгатькә алдан бара. Шуңа күрә бездә ул 9 Майга туры килә дә.*

СССР чорында 9 Майда хәрби парадлар ел саен оештырылмый, аларны бары юбилей елларында гына күрергә мөмкин була. Парадлар туксанынчы еллардан соң гына даими уздырыла башлый. 2008 елда оештырылган парадта исә сугыш техникасы белән бергә хәрби авиация дә катнаша.

Бу көнне һәр җирдә, Җиңү бәйрәменә багышлап, митинглар, кичәләр, концертлар, парадлар уздырыла. Яу кырында ятып калган солдатлар исемлеге язылган һәйкәл алдына чәчәкләр куела. Сугыш ветераннарына исә аерым хөрмәт күрсәтелә. Аларга бүләкләр, чәчәкләр тапшырыла, президентыбызның котлавы җиткерелә.

Бөек Ватан өчен барган канкойгыч сугышта миллионлаган солдатлар яу кырында ятып кала, күбесе хәбәрсез югала, яралана... Илебезгә аларның бик азы гына әйләнеп кайта. Бу сугышта катнашкан барлык сугышчылар алдында бүген бөтен кешелек баш ия.

*Роберт Миңнуллин*

## ТЫНЫЧЛЫКНЫҢ ТУГАН КӨНЕ

Минем бабай орденнарын,
Медальләрен такты бүген.
Ялт-йолт итеп тора алар –
Шуңа күрә якты бүген!

Бүген бигрәк егетләрчә,
Солдатларча атлый бабам.
Бабам белән, җитәкләшеп,
Мин парадка бүген барам.

Җиңүчеләр кебек итеп
Атлыйм мин дә, атлый ул да.
«Син – батыр!» – дим мин бабама,
«Син – батыр!» – дип мактый ул да.

Ул иң батыр солдат булган,
Мин дә солдат булачакмын.
Бабам тыныч ял итсен дип,
Ил чигендә торачакмын!

Борчылмагыз! Үсеп килә
Батырларның оныклары.
Бабайларның батырлыгын
Бер малай да онытмады.

Иртә тусам, мин үзем дә
Бабам кебек булыр идем...
Тынычлыкның туган көнен
Бәйрәм итә бүген илем!

*Әхмәт Исхак*

## КИРӘКМИ БЕЗГӘ СУГЫШ

*(кыскартып бирелә)*

Кирәкми безгә кан кою,
Кирәкми безгә сугыш!
Безнең теләк якты, матур,
Тыныч хезмәт һәм тормыш.

Илебез зур, җиребез киң,
Хисапсыз байлык бездә!
Җир өстендә, җир астында,
Тауларда һәм диңгездә.

Без үз кулларыбыз белән
Төзибез гүзәл тормыш.
Без – тыныч ил төзүчеләр,
Кирәкми безгә сугыш!

*Энҗе Мөэминова*

## МОҢСУ БӘЙРӘМ

Бәйрәмнең тагын да
Матуры, олысы,
Кояшлы май кебек
Яктысы, җылысы –
Бабамның сугышта
Кан коеп алганы –
Зур җиңү бәйрәме
Дигәне бар әле!

Өр-яңа кулмәген,
Иң матур костюмын
Кия дә бабаем
Ул көнне өстенә,
Сандыктан ала да
Күп төрле орденнар,
Медальләр тага ул
Пиджагы түшенә.

Урамнар бәйрәмчә
Бизәлгән булса да,
Кояш гел һавадан
Нур чәчеп торса да,
Кешеләр ул көнне
Кайгылы тоела.
Елыйсын китереп
Яңгырый җыры да.

Ул көнне кешеләр
Һәйкәлләр каршында,
Баш иеп, тын гына
Торалар барысы да.
Һәйкәлләр тирәсе
Чәчәккә күмелә.
Шул чакта минем дә
Яшь килә күземә.

*Эльмира Шәрифуллина*

## МИНЕМ БАБАЙ

Минем бабам – капитан,
Сугышта булып кайткан.
Күкрәк тулы орденнар,
Медальләр алып кайткан.

Безнең илдә һәр бала
Уйнап-көлеп йөрсен дип,
Хәвеф-хәтәр күрмәсен,
Тыныч булып үссен дип,

Көрәшкән чакта бабам,
Әни
Нәкъ минем яшьтә булган,
Рәсем ясап, хат язып,
Бабама салып торган.

Бик күп сугышкан бабам,
Дошманны җиңеп кайткан.
Үзе белән ул безгә
Тынычлык алып кайткан!

*Рафис Корбан*

## ҖИҢҮ БӘЙРӘМЕ

Тугызынчы май –
Җиңү бәйрәме.
Бәйрәмнәрнең иң
Зуры, мөгаен.
Бөтен ил белән,
Яше һәм карты
Бәйрәм итәбез
Аны ел саен.

Безнең Ватанны
Ташларга буып
Килгән фашистлар
Күп еллар элек.
Безнең солдатлар
Явыз дошманны
Газиз Ватаннан
Түккән себереп.

Ул көннән инде
Күп еллар үтте,
Еракта калды
Ул җиңү таңы.
Ләкин беркем дә
Җуймый хәтердән,
Саклый исендә,
Онытмый аны.

***Резеда Вәлиева***

## ҺӘЙКӘЛЛӘР ЯНЫНДА

*(кыскартып бирелә)*

Мәйданнар ягына
Кешеләр агыла.
Ялкындай уйнаклап,
Байраклар кагына.
Кешеләр агыла
Һәйкәлләр янына.
Кешеләр ничә ел
Улларын сагына.
Бик урау булдымы
Җиңүнең юллары,

Ничә ел көтеп тә
Кайтмады уллары.
Мәңгегә калды алар
Тынычлык сагында.
Сагышлы күзләрдә
Энҗеләр чагыла...
Зур бәйрәм тирәли
Моң йөри шым гына.
Кешеләр улларын
Хөрмәтләп тын гына
Башларын игәннәр
Һәйкәлләр янында.
Кайгылы йөзләрдә
Горурлык чагыла:
Бүген ул балалар
Бәйрәмгә килмәгән.
Тик алар Ватанны
Дошманга бирмәгән.
Тетрәнгеч яралар
Онытылсын, калсын, дип,
Туган җир күкрәге
Иркен тын алсын дип,
Балалар калдылар
Тынычлык сагында.

*Шәйхи Маннур*

## БУЛМАСЫН

Минем әти капитан,
Германиядән кайткан.
Утлар, суларны кичкән,
Берлинга барып җиткән.

Фашистларны җиңгән ул,
Сугышны бетергән ул,
Илдә бөтен кешегә
Тынычлык китергән ул.

Минем дәү кызым, дигән,
Тыныч укысын, дигән,
Аның дус кызлары да
Шундый ук булсын, дигән.

Ләйлә белән Камилнең,
Сөмбел белән Наилнең
Әтисе дә сугышкан,
Безнең өчен тырышкан.
Алар бергә йөргәннәр,
Бергә-бергә җиңгәннәр.
Инде минем әтием,
Кабат аерылмабыз, ди.
Үзебез исән чакта,
Сугыш булдырмабыз, ди.

Әллә кайда, еракта,
Комсызлар торган якта –
Тагын телиләр, имеш,
Булсын дип сугыш, үлеш.

Булмасын ул, булмасын,
Кирәкми безгә сугыш!
Булмасын бер куркыныч,
Булсын бөтен ил тыныч!

*Самат Шакир*

## БАБАМНЫҢ МЕДАЛЬЛӘРЕ

Бабамның медальләре күп,
Яңа костюмы тулы.
Тик бабамның – разведчикның
Терсәктән юк сул кулы.

Батырлыгы өчен аңа
Унлап медаль биргәннәр.
Алар шул куркак булмаган,
Разведкага йөргәннәр!

Немецлар тылына кереп,
«Тел» алып кайткан чакта,
Бомбалар шартлап ярылган
Туктаусыз алда, артта.

Менә шунда яраланган
Бабамның сыңар кулы.
Таза чакта ничә тапкыр
Айкаган немец тылын.

Ерак илләрдә булган ул,
Бик күп шәһәрләр алган!
Яңа батырлыклар эшләп,
Медальләр тага барган.

Мин сокланып карыйм аңа,
Баһадир безнең бабай!
Әмма үзе бик аз сүзле,
Мактанмый бер дә алай.

## САБАНТУЙ БҮГЕН БЕЗДӘ!

*(Сабантуй бәйрәме)*

Сабантуй — халкыбызның иң көтеп алынган һәм яратып уздырыла торган бәйрәмнәренең берсе. Ул — татар халкының уңганлыгын, булганлыгын, тырышлыгын, сәләтен, көчен ачып бирә торган бәйрәм. Сабантуй үз эченә бик күп этапларны ала. Әлеге бәйрәм карлар эри башлаганнан алып язгы чәчүгә кадәр булган вакытта уздырылган.

Җир кардан ачыла башлауга ук, «Карга боткасы» бәйрәме оештырылган. Ул Сабантуйга әзерлек булып хезмәт иткән. «Карга боткасы»н еш кына «дәрә боткасы», «зәрә боткасы» бәйрәме дип тә атап йөрткәннәр. Пешерелгән боткадан һәр кешегә өлеш чыгарылган. Ботканы шулай ук каргаларга да, җир-суларга да атап калдырганнар.

Ботка пешергәннән соң, Сабантуй бәйрәменә берничә яки бер көн кала, өй борынча йөреп, манган йомырка җыю йоласы булган. Хуҗалар бу көнне балаларга, кичтән үк әзерләп куелган йомыркалар белән беррәттән, башка күчтәнәчләр дә биреп чыгарганнар. Бала-чага ул көнне олы бәйрәм итеп көтеп алган. Йокылары уяу булсын өчен, алар баш асларына мендәр урынына утын агачы салганнар. Йортка беренче булып керүчеләргә исә күчтәнәч күбрәк эләккән. Балалар юмарт, уңган хуҗаларга исәнлек-саулык, иминлек теләгәннәр.

Шушы көннәрдә үк Сабантуйга бүләк җыю йоласы да үткәрелгән. Бүләкләр ярыш-бәйгеләрдә җиңеп чыгучылар өчен җыелган. Дугасына кыңгыраулар тагылган купшы ат арбасына озын колгалар бәйләнгән. Җыелган сөлгеләр, яулыкларны шул колгага бәйли торган булганнар. Яшь киленнәр биргән сөлге иң

кадерле бүләк саналган. Килен аны Сабантуй бәйрәме өчен махсус әзерләгән.

Бүләк җыю тәртибе һәр җирдә бер үк булган. Әгәр берәр йортка кермичә, читләтеп үтеп китсәләр, хуҗалар үпкәләгәннәр. Бүләк бирүчеләр «монысы көрәшчегә», «чабышта җиңүчегә», «иң арттан килүчегә» дип тә атап бирә торган булганнар.

Элек Сабантуй уздыруның төгәл датасы булмаган. Ул елның нинди булуына, җирнең өлгерүенә караган. Төгәл көнен авыл картлары җыелып хәл иткән. Якын-тирә авыллардагы Сабантуйлар төрле көнне үткәрелгән, чөнки бер-берсенең Сабантуйларына күршеләр бик теләп килгәннәр.

Кайбер төбәкләрдә Сабантуйга кадәр егетләрнең атларда чабышу йоласы да уздырылган. Ул «ат аягы кыздыру» дип аталган.

Сабантуй өчен тигез урынлы җир сайланган. Гадәттә, аның тирә-ягы агач-куаклар белән әйләндереп алынган була. Бу урынны «мәйдан» дип атап йөрткәннәр. Бәйрәм көнне авылның яше-карты иң матур киемнәрен кигән, иң тәмле ашларын пешергән.

Ярышларның иң кызыгы, иң зурысы ат чабышы һәм көрәш булган. Көрәштә батыр калган егеткә тәкә биргәннәр. Моннан тыш чүлмәк вату, колгага әтәч алырга менү, су ташу, гер күтәрү һ.б. кебек уеннар да уздырылган. Сабантуй бәйрәме халыкның бер-берсе белән чын күңелдән аралашу, танышу бәйрәме дә булып торган.

Кич исә яшьләр җыены үткән. Көндез уздырылган бәйрәм урынына яшь кызлар, егетләр җыелып күңел ачканнар.

Бүген исә Сабантуйның йолалары бераз үзгәрде. «Карга боткасы», йомырка җыю, «ат аягы кыздыру» бөтенләй үткәрелми. Калган этаплары исә саклана. Сабантуй бәйрәме инде дәүләт бәйрәме дәрәҗәсенә күтәрелде. Аны Татарстанда, Россиядә генә түгел, чит илләрдә дә бәйрәм итә башладылар.

*Роберт Миңнуллин*

## САБАНТУЙДА

Колга тора мәйданда –
Биегрәктер Айдан да!

Әтәч – колга башында,
Кызыктыра барсын да!

Тик меналмый беркем дә,
Мин дә бар шул төркемдә.

Менә миңа да чират.
Менәм,
Мин дә бит ир-ат!
Менеп киттем тиз генә,
Тиз генә, җитез генә!

Һәм карадым түбәнгә –
Ай-яй... биек менгәнмен,
Ничек менә белгәнмен?!

Ничекләр төшим җиргә? –
Куркыта карарга да.
Торам шулай, килалмый
Бернинди карарга да...

Үч иткәндәй, әтәч тә,
Бөтен көчкә кычкырып,
Китте кулдан ычкынып!

Ычкынды, җиргә очты,
Йоны гына – учымда.
Әтәч урынына мин
Калдым колга очында.

Кирәкми әтәчегез,
Кирәкми бүләгегез –
Мине алырга гына
Менегез берәрегез!

## САБАНТУЙ БҮГЕН БЕЗДӘ

Шатлыклар – күңелебездә,
Ал кояш – күгебездә.
Килегез, дуслар, кунакка,
Сабантуй бүген бездә.

Иң уртага утыртканнар
Иң озын бер колганы –
Колганың да бик тиз генә
Менеп булмый торганы.

Җиңгиләр биреп җибәргән
Бизәкле бүләкләрен,
Ә малайлар көрәшергә
Сызганган беләкләрен.

Ә кызлар киеп чыкканнар
Иң матур күлмәкләрен.
Латыйп бабай төяп килгән
Иң ныклы чүлмәкләрен.

Абыйлар алып килгәннәр
Иң җитез юртакларын.
Гармунчылар алып чыккан
Җырларның уртакларын.

Җилферди чиккән сөлгеләр,
Бүләкләр – күбебезгә!
Көрәшик тә, узышыйк та –
Сабантуй бүген бездә!

*Галимҗан Латыйп*

## ИРТӘГӘ САБАН ТУЕ

Авыл гөж килеп тора,
Килә безгә кунаклар
Районнан, күрше авылдан,
Әллә каян, еpактан.

Сабан туе җитә дип,
Әзерләндек без аңа.
Исәп бар йөгерештә
Малайларны узарга.

Урамда бүләк җыялар,
Сыгыла колга башы.
Кайчакта такмак әйтешеп
Алалар кара-каршы.

Әй бүләге-бүләге,
Атлас икән күлмәге.
Шул бүләкне алам дип,
Тибә батыр йөрәге!..

Мактыйлар бүләкләрне,
Уены-чыны бергә.
Без ияреп йөрибез,
Калу юк инде бер дә.

Урам тулып җыр йөри
Көндезен, кичен, иртән.
Ник бу Сабантуйлары
Көн саен булмый икән?

*Галимҗан Гыйльманов*

## ТӘРТИП БОЗЫП ЙӨРДЕМ

Туйганчы бер!..
Рәхәтләнеп!..
Котырып йөрдем бүген.
Бүген генә ул...
Мин алай
Тәртипсез малай түгел...

Малайлар белән көрәшеп,
Тирләдем, яныл-пештем.
Багана башына менеп,
Ак әтәч урлап төштем.

Чүлмәк ватып йөрдем аннан,
Аркан тартып уйнадым.
Иң ахырдан капчык белән
Бер малайны кыйнадым.

Акча эзләп, башым белән
Ачы катыкка кердем...
...Бүген мин, «тәртипсезләнеп»,
Сабан туенда йөрдем!

*Бари Рәхмәт*

## САБАН ТУЕНДА

*(кыскартып бирелә)*

Безнең авыл янында,
Каенсар урманында
Бик зур Сабан туе була
Һәр ел июнь аенда.
Әтиләр дә бар анда,
Әниләр дә бар анда,
Бабайлар да, әбиләр дә,
Бәбиләр дә бар анда.

Йөгерешәләр бер якта,
Капчык киеп аякка,
Баралар да абыналар,
Китә алмыйча еракка.

Чүлмәк ватыш уены
Бигрәк тә кызык инде.
Әти дә уйнап карады
Бу кызыклы уенны.

Әти китте уң якка,
Чүлмәк калды сул якта.
Таяк ничек тисен инде,
Бер чакрым бар чүлмәккә.

Халык көлә, мин көләм,
Мин көлгәч, әни көлә,
Ничек чыдарсың көлмичә
Шундый кызык көлкегә.

*Ләбиб Лерон*

## САБАН ТУЕ, САБАН ТУЕ...

Әгәренки-мәгәренки,
Көтмәгәндә алай-болай,
Очар тәлинкәдән ялгыш
Төшеп калса берәр малай...
Нинди булыр икән уе –
Күрсә безнең Сабан туен?
Ничек алыр сулышкаен,
Күрсә әгәр ике малай
Капчык белән сугышканын?
Күзе челт-мелт итәр микән,
Күргәч чүлмәк ваткан чакны?
Тынсыз калып торыр микән,
Күргәч атлар чапкан чакны?
Ниләр уйлар күрсә әгәр
Капчык киеп йөгергәнне,
Озын колганың очыннан
Чуар әтәч төшергәнне?
Олы-чага, кызый-мызый,
Авызына кашык кабып,
Шул кашыкка күкәй салып
Йөгергәнне күрсә әгәр,
Торыр микән хәйран калып?
...Нәп-нәкъ шулай булыр иде,
Миндәй хәйран калыр иде.

*Эльмира Шәрифуллина*

## САБАНТУЙ

Сабантуймы, Сабантуй –
Уеннар туе бит ул,
Тәм-томнар сые бит ул,
Җиңүләр уе бит ул.

Чаптар өстендә чабып,
Катыктан тәңкә табып,
Колга башына менеп,
Узышлыга йөгереп...

Татарча бил алышып,
Аркан белән тартышып,
Ватмый йомырка ташып,
Үткенлектә сөйләшеп.
Җиңсәң әгәр,
Сабантуй –
Эчкә шатлык сыймас туй!

*Фәнис Яруллин*

## САБАНТУЙ

Бүген бездә Сабантуй,
Эшләреңнең барын куй.
Тизрәк йөгер мәйданга:
Бәйрәм башлана анда.
Кемдә нинди һөнәр бар?
Йөгерергә кемнәр бар?
Кызганмый табаннарны
Урагыз мәйданнарны.

Ә көрәшә кайсыгыз?
Көч сынашып кайтыгыз.
Курыкмагыз егылудан,
Йөгереп артта калудан.
Ансыз булмый Сабантуй,
Колагыңа киртләп куй.
Булмаса һөнәрегез,
Читтән карап йөрегез
Картлар чүлмәк ватканын,
Атлар чабышып кайтканын,
Көрәшчеләр бер-берсен
Җилкә аша атканын.
Карасагыз – бәйрәм бар,
Сусасагыз – әйрән бар,
Ял итәрсез арсагыз,
Үкенмәссез барсагыз.

*Рафис Корбан*

## САБАН ТУЕ

Сабан туе, Сабан туе,
Без бакчада уйныйбыз.
Ярышабыз, узышабыз,
Матур җырлар җырлыйбыз.

Билгә сөлге салабыз да
Көрәшергә чыгабыз.
Әле батыр булмасак та,
Үскәч чынлап егарбыз.

Иң өлгерләр, иң җитезләр
Бүләк яулап алалар.
Бөтен җирдән җыелганнар
Сабантуйга балалар.

*Газинур Морат*

## САБАНТУЙ

Ник безгә дә көрәшмәскә,
Мәйдан тотмаска әле.
Көрәшик әйдә бергәләп,
Бүген бит яз бәйрәме.

Сабан туенда көрәшеп
Бил бирмәскә өйрәник.
«Без һәрвакыт әзер!» – дигәч,
Җиңелмәскә өйрәник.

Куәтебез ташып тора,
Һәркемдә ярсу йөрәк.
...Без беләбез: әтиләргә
Лаеклы алмаш кирәк!

## МӘКТӘПКӘ БАРАМ!

*(Белем көне)*

Белем көне — ул чәчәкләр һәм ак тасмалар бәйрәме. Бу көнне һәр укучы, чәчәк бәйләме тотып, уку йортына ашыга. Күпләр бу бәйрәмне «Беренче кыңгырау» бәйрәме дип тә атап йөртәләр, чөнки нәкъ менә бу көнне мәктәп балалар бакчасыннан килгән «яңа» укучыларын каршы ала. Ап-ак тасма бәйләгән, кулларына кечкенә портфель тоткан укучылар беренче тапкыр белем йорты бусагасын атлап керә, беренче укытучылары белән очраша, беренче кыңгырау тавышын ишетә.

1 сентябрь рәсми рәвештә «Белем көне» дип беренче тапкыр 1984 елда игълан ителә. Бу көнне һәр укучы бәйрәм итә. Шулай да «Белем бәйрәме»н беренче сыйныфка баручылар аерым бер дулкынлану белән көтеп алалар.

Бәйрәм көнне линейка уздырыла. Анда беренчеләрне мәктәпкә кабул итәләр, кечкенә укучылар үз һөнәрләрен күрсәтәләр. Әкият герое Белмәмеш исә аларга, фәннәрне нык-лап үзләштерер өчен, «белем ачкычы» тапшыра. Беренче кыңгырау, дәрес башлануын белдереп, классларга дәшә.

*Бари Рәхмәт*

## МӘКТӘПКӘ!

Чәчәкләр тотып кулга,
Без чыктык матур юлга.

Һәркем белә, әлбәттә,
Без барабыз мәктәпкә!

Безне котлый әтиләр:
– Бик дәү үстегез! – диләр.

Өйрәтәләр әниләр:
– Әйбәт булыгыз! – диләр.

Дәү әти, дәү әниләр:
– Хәерле юл, хуш! – диләр.

*Зәкия Туфайлова*

## УКЫРГА БАРАМ

Алтын яфрактан,
Алсу яфрактан,
Бәйрәмчә итеп
Көз ник киенгән?
Ашлыгы уңган,
Җимеше мулдан,
Буралар тулган,
Шуңа сөенгән.

Кызыл алкалар,
Төймәләр тагып,
Нинди шатланып,
Иркен тын алып
Утыра балан.
Һәй, киң яланнар,
Миләш, баланнар!
Мин сездән дә шат,
Мин көздән дә шат.
Мин беренче кат
Быел мәктәпкә укырга барам!

*Хәкимҗан Халиков*

## ИҢ ШАТЛЫКЛЫ КӨНЕМ

Яңгыр яуса, ява бирсен –
Чалт аяз күк миңа бүген.
Минем кебек көләч йөзле
Гүя бөтен дөнья бүген...

Сумкамны да ничә ачып,
Ничә тапкыр яптым бүген.
Мин үземә никадәрле
Яңа дуслар таптым бүген!

Белмим кая басканымны,
Бии-бии йөрим бүген.
Барысы да котлый мине,
Иң шатлыклы көнем бүген:
Мин укырга кердем бүген!

*Әнәс Кари*

## БЕРЕНЧЕ КӨН

Озата чыкты әнисе
Капкага кадәр.
Кошчык шикелле очынып
Атлады Әнвәр.

Беренче сентябрь бүген...
Җиде яшь аңа.
Беренче тапкыр ул
Укырга бара.

Иңенә матур сумкасын
Аскан ул, җайлап.
Анда өр-яңа дәфтәрләр,
Өр-яңа китап.

Шушы китабыннан укып,
Хәрефләр таныр;
Көн саен ачып яңа бит,
Күп белем алыр.

Шуңа ул сөенеп атлый,
Җиде яшь аңа.
Беренче тапкыр менә ул
Укырга бара.

*Җәүдәт Дәрзаман*

## БӘЙРӘМ

Балаларга бәйрәм бүген,
Бөтен урам гөж килә.
Һәр сүздән бер кызык табып,
Малайлар, кызлар көлә.

Гөлназ шулар арасында,
Кулда – чәчәк бәйләме.
Күңелләрдә шатлык кына,
Бүген – чәчәк бәйрәме.

Бөтен җирдә чәчәк кенә:
Урамда да, өйдә дә.
Чәчәк чыңы ишетелә
Яңгыраган көйдә дә.

Шул җырларны тыңлый Гөлназ,
Кызык аңа бары да.
«Гөлназ мәктәпкә бара!» – дип
Җырлый китаплары да.

*Мөхәммәт Әхмәтталиев*

# БЕРЕНЧЕ КӨН

Әтәч кычкырды күптән,
Кояш елмайды күктән.
Тәмле төшләр күрдек без,
Күктә очып йөрдек без.
Бүген иртә уяндык,
Көнгә карап куандык.
Их, сикердек, шатландык,
Кош кебек канатландык.
Сентябрьнең бере ич,
Бүген уку көне ич.
Сикерешеп тордык без,
Бит-кулларны юдык без,
Ашап-эчеп киендек,
Шау-гөр килдек, сөендек.
Китап-дәфтәрләр салдык,
Матур сумканы алдык.
Бик күңелле сөйләшеп,
Шаулашып та гөрләшеп,
Иң беренче мәртәбә
Җыйналдык без мәктәпкә.

*Ренат Харис*

## БЕЛЕМ МАРШЫ

*(җыр*)*

Шатланып ачып керәмен
Мәктәп ишеген, –
Белемнең зур көч икәнен
Белгән кеше мин.

Яңгыра, көмеш кыңгырау,
Безне каршыла, –
Кушыл әйдә һәм куәт бир
Белем маршына!

Шатланып ачып керәмен
Мәктәп ишеген.
Бар көчемне биреп уку –
Минем төп эшем.

Шатланып ачып керәмен
Мәктәп ишеген, –
Ишетәмен Ватанымның
Йөрәк тибешен.

---

* Резеда Ахиярова музыкасы.

*Муса Җәлил*

## БЕРЕНЧЕ ДӘРЕС

Без бу ел гына
Мәктәпкә килдек.
Аңарчы һаман
Бакчада идек...

Мәктәп өр-яңа,
Анда парталар,
Алар күңелне
Эчкә тарталар.

Кулыбызда безнең
Яңа Әлифба.
Менә монысы «а»,
Менә монысы «ба».

Без хәрефләрдән
Сүзләр ясыйбыз,
Шуннан соң җырлап
Укый башлыйбыз:

Ат,
ата,
арта.
Ат арба тарта.
Ата-аналар
Атта баралар.

Нинди зур бәхет,
Нинди үзгәреш!
Бигрәк күңелле
Беренче дәрес!

*Ләбиб Лерон*

## МИН МӘКТӘПКӘ БАРАМ

Китап-дәфтәр аламын,
Күн букчама саламын...
Күрегез сез, карагыз сез –
Мин мәктәпкә барамын!

Кулларымда – чәчәкләр...
Мин үзем дә чәчәк күк!
Мин барасы юлга гына
Кояш нурын чәчә күк.

Карап калды бабай да,
Карап калды әби дә.
«Мин дә барам мәктәпкә!» – дип
Елап калды Нәби дә.

Чаба артка калып та,
Чаба мине узып та –
Мәктәбемә минем белән
Бара бүген Тузик та!

## СӨМБЕЛӘНЕ КЕМ БЕЛӘ?

*(Уңыш бәйрәме — Сөмбелә бәйрәме)*

Урып-җыю эшләре тәмамлангач, халкыбыз Уңыш бәйрәмен — Сөмбелә бәйрәмен уздыра торган булган. Ул көн белән төн тигезләшкән вакытка (21—23 сентябрьгә) туры килгән. Уңыш, җыелып, келәт-амбарларга тутырылгач, халык бик зурлап бәйрәм уздырган.

«Сөмбелә» сүзе гарәпчәдән «башак, бөртек, орлык, иген» дип тәрҗемә ителә. Ә бәйрәмнең «Сөмбелә» дип аталуы Уңыш алиһәсенең исеменнән алынган. Татар халкы элек-электән игенчелек белән шөгыльләнгән. Ислам дине кабул ителгәнче үк, безнең бабаларыбыз Җир-Су аллаларына табынганнар. Фольклор әсәрләрендә, мифларда Җир алласын Җирән Сакал, Су алиһәсен Асылбикә, Уңыш алиһәсен Сөмбелә дип атаганнар.

Бәйрәмнең хуҗасы Сөмбелә алтын-сары төстәге толымлы кыз булган. Аны иң уңган, иң чибәр кызлар арасыннан сайлап алганнар һәм, матур итеп киендереп, мәйданга алып чыкканнар. Сөмбеләнең башына алтын башаклардан такыя үреп кидергәннәр. Ил агайлары Сөмбеләне келтәләр белән бизәлгән тәхеткә утыртканнар. Кызга төрле сораулар биргәннәр: «Балтамы, әллә безме?» Сөмбелә: «Балта!» — дисә, көз салкын булачак, бозны балта белән дә вата алмассың, имеш. «Без!» — дисә, көз җылы киләчәк, елгадагы бозны без белән дә тишеп булачак, дип уйлаганнар.

Сөмбелә бәйрәмен бүген дә бик күңелле итеп бәйрәм итәләр. Аның иң матур үрнәкләрен авыл мәктәпләрендә күрергә була. Балалар берничә көн алдан шигырьләр, җырлар өйрәнәләр, уеннар әзерлиләр. Бәйрәм көнне яшелчә, җиләк-җимешләр, башак-

лар белән өстәл бизиләр. Монда биш чатлы кишерне дә, колач киңлегендәге кабакны да, төймә зурлыгындагы помидорны да күрергә була. Иң уртага — түргә икмәк куела. Өстәлне бизәүдә шулай ук сары яфракларны, кызыл миләшләрне, баланнарны да кулланалар.

Укучылар бөртек аеру, бәрәңге чүпләү, бәйләү, суган әрчү буенча бәйгеләр үткәрәләр. Барлык бәйгеләрдә җиңеп чыккан кыз сыйныфның йә мәктәпнең Сөмбеләсе исеменә лаек була. Аңа башаклардан ясалган такыя яки чәчәкләрдән үрелгән калфак кидерәләр.

### *Син беләсеңме?*

*Сөмбелә бәйрәмендә өстәлгә һәрвакыт бавырсак куйганнар. Ул көзге муллык, байлык символы булган.*

*Әхмәт Ерикәй*

# УҢЫШ

Үсеп утыра арыш,
Һәр башагы бер карыш.
Бодай үсә ургылып,
Дулкынланып, зур булып.

Әгәр күрсәң солысын –
Исең китеп торырсың.
Әнә кара тарыга,
Үрмәли югарыга.

Зәңгәр чәчәкле җитен –
Читләтеп үтү читен.
Киндер дә бигрәк уңган,
Әйтерсең кара урман.

Кәбестәләр, суганнар
Түтәлләргә тулганнар.
Кишер белән чөгендер –
Тик җыеп кына өлгер.

*Галимҗан Латыйп*

## АЛМА ҖЫЯБЫЗ

Урман-кырларга
Килде матур көз.
Җәй үтте диеп
Үкенмибез без.

Бакчада хуш ис,
Бакчада ямьле.
Берсеннән-берсе
Алмалар тәмле.

Без, шау-гөр килеп,
Алма коябыз.
Алны тутырып,
Алма җыябыз.

Әниләр безгә:
– Булдырасыз! – ди, –
Бездән дә инде
Уздырасыз! – ди.

Без аның саен
Шатланышабыз.
Әниләр белән
Без ярышабыз.

*Фәнис Яруллин*

## КӨЗГЕ ТАБЫН

Көзге табын – бай табын,
Кыяр, карбыз һәм кавын
Телем-телем теленгән,
Өем-өем өелгән.

Алмалары ал төсле,
Балкып туган таң төсле.
Капсаң, эри авызда,
Һәр кисәге бал төсле.

Ә җимеше, җимеше,
Ачысы бар, төчесе!
Яңа пешкән күмәчтер
Кайнар кояш төслесе.

Әткәм кебек тырыш көз,
Әнкәм кебек юмарт көз.
Көзләр юмарт булганга,
Бик бәхетле, бик шат без.

*Гөлшат Зәйнашева*

## СӨМБЕЛӘ

*(җыр*)*

Сөмбелә дип матур исем
Кушты икән кем генә?
Сөмбел гөлдән өзлеп төшкән
Чәчәк кебек Сөмбелә.

Кушымта:

Сөмбелә, Сөмбелә,
Сөмбел гөлдән өзлеп төшкән
Чәчәктер ул, кем белә?

Әткәсенә, әнкәсенә
Ул күз карасы кебек.
Гөл арасында сайраган
Былбыл баласы кебек.

Кушымта:

Сөмбелә, Сөмбелә,
Гөл арасында сайраган
Былбылдыр ул, кем белә?

Чәчәк кебек сөйкемле ул,
Былбыл кебек моңлы ул.
Таң аткач та сүнми торган
Йолдыз кебек нурлы ул.

Кушымта:

Сөмбелә, Сөмбелә,
Таң аткач та сүнми торган
Йолдыздыр ул, кем белә?

---

* Мәсгудә Шәмсетдинева музыкасы.

*Ленар Шәех*

## СӨМБЕЛӘ

Табыннар сыгылып тора
Ул сыйдан, ул нигъмәттән.
Алмалары ташып чыккан
Баллы, татлы ширбәттән.

Ташкабак менеп утырган
Уртага, бәлеш булып.
Кайнатма, бал, кыстыбыйдан
Өстәлләр тора тулып.

Ит бәлеше дә күренә,
Хәтта өчпомагы да.
Гөмбәнең ниндие кирәк –
Майлысы да, агы да.

Кура җиләге һәм чия
Компотка әверелгән.
Кемдер исә муенына
Миләш-муенса элгән.

Ак күмәч, ак ипи булып,
Түрдән икмәк нур сибә.
Мондый тәм-томнарны күргәч,
Авыздан сулар килә.

Биибез дә, җырлыйбыз да,
Уеннар да уйныйбыз.
Киләсе елга да уңыш
Мул булыр дип уйлыйбыз.

Иртә яздан тырыштык бит,
Тир түктек бакчабызда.
Хезмәтнең нәтиҗәсенә
Сөенә барчабыз да.

Нинди көн, нинди тантана,
Бу бәйрәмне кем беләү?
Бездә Уңыш бәйрәме бит,
Бай һәм юмарт Сөмбелә!

*Нур Гайсин*

## УҢЫШ ҖЫЕЛДЫ

Уңыш җыелды,
Аккошлар китте,
Матур көз ае –
Сентябрь җитте.

Урамнар тулып,
Йөкләр үтәләр,
Алар дәүләткә
Ашлык илтәләр.

Бар да ашыга,
Тизрәк илтик, дип,
Илебезне бай,
Матур итик, дип.

*Шәүкәт Галиев*

## ПОМИДОР-СВЕТОФОР

Помидор-светофор
Ямь-яшел алдымда.
Су сибим, йомшартыйм,
Мин барыйм янына.

Помидор-светофор
Саргая кай ара.
Көз, бераз түз, диям,
Әйтерсең шаяра.

Помидор-светофор,
Син пештең кызарып.
Туктыйм да сокланам,
Киталмыйм кузгалып.

*Хәкимҗан Халиков*

## ИПЕКӘЙ

Бала:

Яхшы беләм игеннең
Кара җирдә үскәнен,
Урган чакта этинең
Манма тиргә төшкәнен.
Нигә алтын төсле соң
Ындырдагы көшелләр?

Ипекәй:

Үстергәнгә кадерләп
Алтын куллы кешеләр.

Б а л а:

Оны ап-ак! Бу аклык
Каян килгән соң аңа?

И п е к ә й:

Ак булган ул, игенче
Күңеле ак булганга.

Б а л а:

Ашаганда телемне
Йота яздым әле мин.

И п е к ә й:

Беләсеңме, әниең
Пешергәнгә тәмле мин.

Б а л а:

Валчыгын да калдырмыйм
Ашаганда табында.

И п е к ә й:

Әгәр эшләп ашасаң,
Тәмлерәк мин тагын да.

Б а л а:

Кайдан алып безгә син
Шулкадәр көч бирәсең?

И п е к ә й:

Миңа күпме кешенең
Көче кергән, беләмсең?

*Роберт Миңнуллин*

## БАЛАЧАК БӘЙРӘМНӘРЕ

Бәйрәмсез бик күңелсез бит –
Күңелсездер сезгә дә.
Бәйрәмнәр кирәк безгә дә,
Бәйрәмнәр кирәк сезгә дә,
Кирәк һәммәбезгә дә!
Бәйрәмнәр кирәк әтигә,
Бәйрәмнәр кирәк әнигә,
Бабай белән әбигә!

Бәйрәмнәр бетмәс берчак та,
Балачаклар бар чакта.
Зур бәйрәм – бишле алсак та,
Кырларда эшләп арсак та,
Зоопаркка барсак та!
Зур бәйрәм – җырлап алсак та,
Җәйге кояшта янсак та,
Походларга барсак та!

Бәйрәмнәр бездә җитәрлек.
Үзе бәйрәм – балачак!
Балачакның шат җырлары,
Балачакның шат еллары
Мәңге истә калачак!
Бәйрәмнәр бик күп булай да,
Ә шулай да, ә шулай да
Иң шәп бәйрәм – балачак!

## ФАЙДАЛАНЫЛГАН ӘДӘБИЯТ

* Балалар календаре / төз. С.Маннапов. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.

* Гөлбакча (Балалар бакчалары өчен хрестоматия) : Балалар бакчаларында эшләүче тәрбиячеләр өчен кулланма. — Казан : Татар. кит. нәшр., 1990.

* Җәләлиев Ш.Ш. Татар халык педагогикасы : татар гимназияләре һәм лицейларының 11 нче с-фы, педагогия колледжлары, училищелары өчен дәреслек-хрестоматия. — Казан : Мәгариф, 2000.

* Урманче Ф.И. Татар халык иҗаты. — Казан : Мәгариф, 2002.

# ЭЧТӘЛЕК


***Габдулла Тукай*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3
Бәйрәм бүген . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

ЯҢА ЕЛ КИЛӘ! *(Яңа ел бәйрәме)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 4
***Данис Хәбибуллин*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
Кермичә китмәс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 7
***Җәвад Тәрҗеманов*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
Яшел чыршы *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 8
***Резеда Вәлиева*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
Яңа ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 9
***Әхмәт Ерикәй*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
Кыш *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10
***Мәрзия Фәйзуллина*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кыш бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
***Әхмәт Рәшит*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
Кыш бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 11
***Хәкимҗан Халиков*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
Кыш бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12
***Әнәс Кари*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Кыш бабай бүләкләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13
Кыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 14
***Нур Гайсин*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Бер яшькә үстем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 15
***Роберт Миңнуллин*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Чыршы әйләнәсендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 16
Кар бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 17
***Әминә Бикчәнтәева*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Чыршы янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
***Галимҗан Латыйп*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
Яңа ел . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 18
***Муса Җәлил*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
Суык бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 19
***Дамир Гарифуллин*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Кар бабай ясадык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
***Сәхаб Урайский*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
Чыршы янында *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 20
***Ләбиб Лерон*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21
Хуш киләсең, Яңа ел! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 21

СОЛДАТ БУЛАСЫМ КИЛӘ! *(Ватанны саклаучылар көне)* . . . . . . . . 22
***Клара Булатова*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Солдатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
***Шамил Маннапов*** . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 23
Солдатта булган, диләр... *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . 23

*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
Почмакта торам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 24
*Җәүдәт Дәрзаман* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
Солдат булдым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 25
*Шәүкәт Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26
Бусы – хәрби сер! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 26

БҮГЕН ӘНИ БӘЙРӘМЕ! *(8 Март – Халыкара хатын-кызлар көне)* . 27
*Гөлшат Зәйнашева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Әниләр бәйрәме *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 29
Кояш гомере *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 30
*Резеда Вәлиева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
Әниләр бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 31
*Фәнис Яруллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Әниләр бәйрәмендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 32
Бүшлык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
*Саҗидә Сөләйманова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Әниләр бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 33
Кем уяткан Ләйләне? . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
*Зәкия Туфайлова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
«Әни» сүзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 34
*Җәүдәт Дәрзаман* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 35
*Җәвад Тәрҗеманов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
Әни турында җыр *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 36
*Ренат Харис* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37
Әнием . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 37

НӘҮРҮЗ КИЛӘ, БЕЛӘСЕҢМЕ? *(Нәүрүз бәйрәме)* . . . . . . . . . . . . 38
*Халык авыз иҗаты* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Торыгыз, тор, хуҗалар!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Нәүрүз, Нәүрүз, хуҗалар!» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
«Чиби-чиби, чип тавык...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 40
Былбылдан аваз килде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
*Әхмәт Гадел* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
Нәүрүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 41
*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Нәүрүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
*Роза Хафизова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42
Нәүрүз килә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 42

САГЫНЫШЫП КОШЛАР КАЙТА *(Халыкара кошлар көне)* . . . . . . 43
*Галимҗан Латыйп* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Кошлар кайткач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
*Энәс Кари* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Хуш килдегез, кошлар! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 44
Минем кунагым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 45

*Нури Арсланов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
Кара карга . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 46
*Нәҗип Мадьяров* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Сыерчык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
*Ләбиб Лерон* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
Сыерчыклар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 47
*Шәйхи Маннур* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
Кошлар килде . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 48
*Гасыйм Лотфи* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Сыерчык . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49

УРА, ҖИҢҮ КИЛДЕ! *(9 Май – Бөек Җиңү көне)* . . . . . . . . . . . . 50
*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
Тынычлыкның туган көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 52
*Әхмәт Исхак* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Кирәкми безгә сугыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Энҗе Мөэминова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Моңсу бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
*Эльмира Шәрифуллина* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Минем бабай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Рафис Корбан* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
Җиңү бәйрәме . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 55
*Резеда Вәлиева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
Һәйкәлләр янында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
*Шәйхи Маннур* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Булмасын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
*Самат Шакир* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
Бабамның медальләре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59

САБАНТУЙ БҮГЕН БЕЗДӘ! *(Сабантуй бәйрәме)* . . . . . . . . . . . . 60
*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Сабантуйда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Сабантуй бүген бездә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
*Галимҗан Латыйп* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
Иртәгә Сабан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
*Галимҗан Гыйльманов* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Тәртип бозып йөрдем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
*Бари Рәхмәт* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
Сабан туенда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
*Ләбиб Лерон* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Сабан туе, Сабан туе... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
*Эльмира Шәрифуллина* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
*Фәнис Яруллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
*Рафис Корбан* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
Сабан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69

*Газинур Морат* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Сабантуй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70

МӘКТӘПКӘ БАРАМ! *(Белем көне)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . 71
*Бари Рәхмәт* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Мәктәпкә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
*Зәкия Туфайлова* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Укырга барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
*Хәкимҗан Халиков* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Иң шатлыклы көнем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
*Әнәс Кари* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
Беренче көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 74
*Җәүдәт Дәрзаман* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
*Мөхәммәт Әхмәтгалиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
Беренче көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 76
*Ренат Харис* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Белем маршы *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
*Муса Җәлил* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
Беренче дәрес . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
*Ләбиб Лерон* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79
Мин мәктәпкә барам . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 79

СӨМБЕЛӘНЕ КЕМ БЕЛӘ? *(Уңыш бәйрәме – Сөмбелә бәйрәме)* . . . . . 80
*Әхмәт Ерикәй* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
Уңыш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
*Галимҗан Латыйп* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
Алма җыябыз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
*Фәнис Яруллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Көзге табын . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
*Гөлшат Зәйнашева* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Сөмбелә *(җыр)* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
*Ленар Шәех* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
Сөмбелә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 86
*Нур Гайсин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Уңыш җыелды . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
*Шәүкәт Галиев* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Помидор-светофор . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
*Хәкимҗан Халиков* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Ипекәй . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88

*Роберт Миңнуллин* . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
Балачак бәйрәмнәре . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90

Файдаланылган әдәбият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91

Литературно-художественное издание

Для детей младшего и среднего школьного возраста

# САМЫЙ ВЕСЁЛЫЙ ДЕНЬ

Редактор-составитель *Калимуллина Эльвира Тальгатовна*

Казань. Татарское книжное издательство. 2011

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Кече һәм урта яшьтәге мәктәп балалары өчен

# ИҢ КҮҢЕЛЛЕ КӨН

Төзүче-мөхәррире *Кәлимуллина Эльвира Тәлгать кызы*

Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Р.Н.Нуриева*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 11.10.2011.
Форматы 70×108 1/32. Шартлы басма табагы 4,2.
Тиражы 3000 д. Заказ Р-1558.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс:(843) 519-45-22

**http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru**

**Безнең китапларны түбәндәге адреслар буенча сатып алырга мөмкин:**

Казан, Декабристлар урамы, 2.
Татарстан китап нәшриятының маркетинг бүлеге. Тел.: (843) 519-45-35.
Казан, Бауман урамы, 29/11.
Татарстан китап нәшриятының фирма кибете. Тел.: (843) 292-03-18.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.